РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
**ГЛАВА**
Агерзинского сельского поселения
Азнакаевского муниципального района

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Азнакай муниципаль районы
Әгерҗе авыл җирлеге Советы
**БАШЛЫГЫ**

ул. Г. Ахметова, д. 14а, село Агерзе,
Азнакаевского муниципального района, 423303
Тел. (факс) 8(8-5592) 44-5-21
E-mail: Ager.Azn@tatar.ru

Г. Әхмәтова урамы, 14а, Әгерҗе авылы
Азнакай муниципаль районы, 423303
Тел. (факс) 8(8-5592) 44-5-21
E-mail: Ager.Azn@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«10» ноябрь 2021 ел № 5

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әгерҗе авыл җирлеге Мәнәвез торак пунктында гражданнарның үзарасалым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенч агражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Азнакай муниципаль районы Әгерҗе авыл җирлеге Уставы белән, **карар чыгарам:**

1.Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әгерҗе авыл җирлеге Мәнәвез авылында теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен 2021 елның 27 ноябрендә 09 сәгать 00 минутта үзарасалым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының беренче этабын билгеләргә: Советская урамы 1 йорттан 54 йортка кадәр; Үзәк урам 1йорттан 75 йортка кадәр. Үткәрү урыны: Мәнәвез авылы, Советская урамы, 1а, мәдәният йорты.

2. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әгерҗе авыл җирлеге Мәнәвез авылында теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен 2020 елның 27 ноябрендә 11 сәгать 00 минутта үзарасалым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының икенче этабын билгеләргә: Болотная урамы 2 йорттан 7а йортына кадәр, Чулпан урамы 1 йорттан 14а йортына кадәр, Зирекле урамы 1 йорттан 11 йортка кадәр, Полевая урамы 40а йорттан 44 кв. 2 йортына кадәр. Үткәрү урыны: Мәнәвез авылы, Советская урамы, 1а мәдәният йорты.

3. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әгерҗе авыл җирлеге Мәнәвез авылында теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен 2020 елның 27 ноябрендә 14 сәгать 00 минутта үзарасалым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының өченче этабын билгеләргә: М.Җәлил урамы 1 йорттан 10 йортка кадәр, Сосновая урамы 1А йорттан 12 йортка кадәр, Алмалы урамы 1 йорттан 12 йортка кадәр, Наратлы урамы 1 йорттан 20 йортка кадәр, Г.Тукай урамы 1 йорттан 7 йортка кадәр, Азатлык урамы 3 йорттан 5 йортка кадәр Үткәрү урыны: М.Җәлил урамы, 1А нче йорты каршында.

4. Билгеләү:

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әгерҗе авыл җирлеге Мәнәвез торак пунктында үзарасалым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы - Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әгерҗе авыл җирлеге Башкарма комитеты;

- халык җыенын үткәрү вакыты-2021 елның 27 ноябре 09.00 сәгатьтән 11.00 сәгатькә кадәр;

- халык җыенын үткәрү вакыты-2021 елның 27 ноябре 11.00 сәгатьтән 13.00 сәгатькә кадәр;

- халык җыенын үткәрү вакыты-2021 елның 27 ноябре 14.00 сәгатьтән 16.00 сәгатькә кадәр;

- җыенны үткәрү урыны-Мәнәвез авылы, Советская урамы, 1а мәдәният йорты;

- җыенны үткәрү урыны-Мәнәвез авылы, Советская урамы, 1а мәдәният йорты;

- җыенны үткәрү урыны-Мәнәвез авылы, М.Җәлил урамы, 1А йорты каршында.

5. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әгерҗе авыл җирлеге башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

- 2021 елның 15 нояберennән дә соңга калмыйча граждannар, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әгерҗе авыл җирлеге Башкарма комитетында, граждannар җыенын хәл итүгә чыгарылучы материаллар белән танышу хокукына түбәндәге адрес буенча ия: Әгерҗе авылы, Г. Әхмәтова урамы, 14а йорт; Мәнәвез авылы, Советская урамы, 1а мәдәният йорты;

- Мәнәвез торак пунктында сайлау хокукына ия яшәүчеләр исемлеген төзергә;

- граждannар җыенына мәгълүмати материаллар әзерләргә;

- Мәнәвез торак пункты халкына массакүләм мәгълүмат чараларында һәм башка ысуллар белән граждannар җыены турында хәбәр итү.

6. Граждannар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2022 елда Әгерҗе авыл җирлеге Мәнәвез торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булганнардан 500 сум күләмендә, 1 төркем инвалидларыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, түләүне бер тапкыр киметеп 80 яшьтән өлкән пенсионерлар өчен 400 сум күләмендә үзарасалым кертү һәм бу акчаларны җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- авыл җирлеге территорияләрен төзекләндерү (Мәнәвез авылы урамнары исеме язылган күрсәткечләр, мәгълүмат стендлары сатып алу(әзерләү);
- спорт мәйданчыгы урнаштыру (мини футбол);
- бәйрәм чараларын оештыру һәм үткәрү (бүләк, сувенир продукция сатып алу, «Җиңү көне», "Сабантуй", «Халыкара өлкәннәр көне», «Корбан бәйрәме», «Яңа ел " бәйрәм чараларын үткәрү буенча хезмәт күрсәтү, спорт чаралары);
- күмү урыннарын карап тоту (чүп-чар җыю һәм чыгару, кусторез сатып алу);
- трактор йөртүчесенә хезмәте өчен түләү.

« РИЗА» «КАРШЫ»

7.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru,

- Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru.

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы, Мәнәвез авылы, Советская урамы, 1а адресы буенча, Мәнәвез авылы, Советская урамы, 29 йорт каршында, Мәнәвез авылы, Узәк урамы, 60 йорт каршында урнашкан Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әгерҗе авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

8. Әлеге карар ул халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Башлык: Н.Н.Хәсәнов

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГЕРЗИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АЗНАКАЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН